УДК 391/395

*Х.Ч. Алишина*

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ТӨРЛЕ ЭТНОГРАФИК ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ ИСЕМ КУШУ КУЛЬТУРАСЫ

Антропонимы татарского народа, будучи в совокупности достаточно многочисленными, имеют свою внутреннюю систему, свои закономерности функционирования, они составляют ценный культурный интересный объект научного исследования. В статье мы старались показать антропонимическую систему, обычаи и обряды наречения именем у различных этнических групп татар России. Татарский именник постоянно пополняется новыми именами, они адаптируются в татарской среде и с течением времени количественно возрастают. Современный антропонимикон представляет единство многообразий этнолингвистических компонентов, характеризующихся разновременностью и разноязычностью их вхождения: это старотатарские, арабские, персидские, русские и западноевропейские имена.

**Ключевые слова:** антропонимы, ислам, астраханские татары, нукратовские татары, крещеные татары, хвалынские татары, вагайские татары, сибирские татары, крымские татары

The anthroponyms of the Tatar people, while quite numerous in their totality, have their own internal system and their own patterns of functioning, constituting a valuable cultural and interesting object of scientific research. In this article, we sought to demonstrate the anthroponymic system, customs, and naming rituals of various ethnic groups of Tatars in Russia. The Tatar name list is constantly being supplemented with new names, which are adapted to the Tatar environment and increase in number over time. The modern anthroponymicon represents the unity of diverse ethnolinguistic components, characterized by their multi-temporal and multi-lingual occurrence: these include Old Tatar, Arabic, Persian, Russian, and Western European names.

**Keywords:** anthroponyms, Islam, Astrakhan Tatars, Nukratov Tatars, baptized Tatars, Khvalynsk Tatars, Vagay Tatars, Siberian Tatars, Crimean Tatars

Ислам – дөньякүләм таралган өч диннең берсе. Ул VII гасырда барлыкка килә һәм Азия, Африка, күп кенә Европа халыкларының тарихын, идея һәм мәдәни тормышын билгели. Ә бу якынча бер миллиард кеше дигән сүз.

Россия татарларының исламга тартылуы прогрессив әһәмияткә ия була. Мөселман йолалары һәм гореф-гадәтләре кешенең көндәлек тормыш ритмын системага сала, табигатьтән бирелгән рухи башлангычны үстерә.

Ислам динен тотучы һәркем тормышын шәригать нормаларына туры китереп кора. Алар иманны билгели, әхлакый кыйммәтләр һәм дини вөҗдан формалаштыра, кешенең үз-үзен тотышын тәртипкә

сала торган конкрет кагыйдәләр чыганагы булып тора. Шәригатьтә кешенең бу дөньяга килүеннән башлап үлеменә кадәрге көндәлек тормыш мәсьәләләре җентекләп яктыртыла: яңа туган балага исем сайлау, йорт салу, урамда, җәмәгать урыннарында, сәяхәттә үз-үзеңне тоту, күршеләр белән мөнәсәбәт кору, авыруларны дәвалау, дөнья белән хушлашу, соңгы юлга озату, каберләрне карап тоту һ. б.

Ислам традицияләре татарларның гаилә йолаларында ачык чагыла. Россиядә яшәүче татарлар да бөтен мөселман дөньясында киң таралган ислам йолаларын үтәп яшиләр. Шундый йолаларның берсе – яңа туган балага исем кушу.

Балага исем туып берничә көн узгач бирелә. Озаграк исемсез калдыру куркыныч санала, чөнки ул авырып китәргә мөмкин. Әлеге тантанага мулла, өлкән яшьтәге туганнар, күршеләр чакырыла. Бала туганнан соң үлгән очракта, исем кушып җирләнә. Татарларның төрле этнотерриториаль төркемнәрендә бу йола бертөрле диярлек башкарыла. Баланы мендәргә салып, мулла янына алып киләләр. Йола азан әйтеп башлана. Аннан соң камәт укыла, һәм баланың ике колагына да исеме әйтелә. Шуннан соң дога укыла: «Йә Аллаһым! Бу балага ислам дине тарафдары булып, тән һәм рух сәламәтлеге белән, әтиәнисенең намуслы, шәфкатьле, игелекле улы булып үсәргә насыйп әйләсен». Намаздан соң мулла гарәп язуында баланың исемен метрика кенәгәсенә терки. Мәҗлеснең йомгаклау өлешендә чакырылган кунакларны сыйлыйлар.

Балага исем сайлаганда, мулланың фикеренә колак салалар, чөнки ул әлеге торак пунктта һәр кешенең кабатланмый торган шәхси исемгә ия булуын күзәтеп тора.

Шәригать буенча мөселман балаларын гарәп исемнәре белән атау яхшырак. Бигрәк тә Мөхәммәд пәйгамбәр сахабәләренең исемнәрен кушу хуплана (Әбүбәкердән кала, чөнки ул «Бәкернең атасы»дигән мәгънәгә дә ия). Гарәпләрдә балага туганда бер исем кушканнар, ә ул, үсеп, үзе әти кеше булгач, аны улының исеме белән, мәсәлән, Әбүбәкер, ягъни «Бәкернең атасы» дип атый башлаганнар. Әйтик, аның чын аты Габдулла булган, ди. Ул чакта аның улы Бәкер гарәпчә Бәкер бине Габдулла дип йөртелә. Әмма, башка халыклардагы кебек, тел чараларын экономияләү законы нигезендә, ул еш кына «Бәкергабдулла» дип кенә әйтелә. Шуңа күрә татарлардагы Әхмәтлатыйп кебек ике компоненттан торган исемнәрне гарәпләр дә шулай ук кабул итә: Әхмәт, Латыйп улы. Аңлашылмаучылык тумасын өчен, муллалар балаларны бер компонентлы исемнәр белән атарга киңәш итәләр.

Кызларга исем сайлаганда ата-аналар аеруча нәзакәтлелек күрсәтәләр, нәтиҗәдә Бибихафизелҗәннәт һәм Бибигөлҗамал кебек исемнәр барлыкка килә. Биби – фарсыча ханым; хафу – каравылчы; җамал – чибәр, гүзәл дигәнне аңлата. «Җәннәтне саклаучы ханым», «Чәчәк кебек матур ханым» мәгънәләре килеп чыга. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында катлаулы исемнәргә алмашка Гайшә, Зәйнәп, Фатыйма һ. б. кебекләр килә [12: 65].

Гарәп телендә «кол» мәгънәсендәге «габд» (габид) сүзе бар. Бала исемендә бу сүзнең Аллаһы Тәгалә эпитетлары белән бергә кулланылуы хуплана, мәсәлән, Габдулла (Габдел-Алла), бу Аллаһның колы дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгаләнең барлыгы йөздән артык эпитеты һәм исеме бар (дөресрәге 103), аларның теләсә кайсысын исем ясау өчен файдаланырга мөмкин [11: 17].

Шулай ук ата-аналарның үз балаларын изгеләр белән «кушылган» итеп күрергә теләве сәбәпле, балага изгеләр исемнәре дә кушалар. Әмма «Габд» сүзен изгеләр исемнәре белән бергә куллану дөрес булмас иде.

Исемнәр арасында иң изгесе – Мөхәммәд, шулай ук пәйгамбәр һәм фәрештәләрнең исемнәре. Аны йөртүче балаларны балачакта да, балигъ булгач та ачуланырга, кыйнарга һәм башкача кимсетергә ярамый. Мөселманнар арасында Мөхәммәд аеруча хөрмәт ителә, һәм шушы исем кушылган бала аңа лаек булырга тиеш, әгәр ул аны акламаса, тормыш юлында авыр сынауларга дучар булачак. Әгәр изге Мөхәммәд исемен йөрткән кеше үзен начар яктан күрсәтсә, ул чиксез хурлыкка дучар булачак. Шуңа күрә шәригать буенча кайбер китаплар үз балаларына фәрештә, пәйгамбәр һәм изгеләр исемнәрен биргән ата-аналарны хупламый.

Керәшен татарлары үз балаларына христиан исемнәрен бирә. Татар сөйләм теленең фонетик төзелеше йогынтысында бу антропонимнар закончалыклы адаптация кичергән: Марья – Маржа, Настя – Начтый, Григорий – Гөргери, Пётр – Питрей һ. б. Авыр тормыш ситуацияләрендә, гаиләдә балалар үлгәндә, керәшеннәр Тимер кебек төрки чыгышлы дини булмаган исемнәр кушалар (көнкүрештә иркәләү-кечерәйтү формасы белән Тимерүк дип атыйлар) [5: 15].

Татарларның төрле этнографик төркемнәрендә балага исем кушу түбәндәге принциплар нигезендә башкарыла: мулла азан укый, аннан баланың ике колагына да исемен әйтә. Аерымлыклар бик аз.

Мәсәлән, Хвалын татарларында балага туганда вакытлыча «кендек аты» бирелә [3: 152–153]. Бер атнадан соң мулланы чакыралар һәм аңа икенче, даими исем кушалар. Бу вакытта балага күлмәк киderәләр, аны, башы белән көнчыгышка каратып, ак мендәргә салалар, мендәрне өстәл өстенә куялар. Мулла аягүрә басып дога укый, аннары баланы әнисенә тапшыра һәм аны үзенең әтисенә түгел, ә иренең өлкән туганына бирергә куша («Үз атаңнан син киттең инде»). Түбән Новгородта исем кушылган баланы әбисенә (әтисе ягыннан) бирәләр, ул баланы бишеккә сала. Ә баланың әнисе моның өчен кайнанасына бүләк бирергә тиеш [8: 14].

Әстерхан татарлары балага исемне туып өч көн узгач кушалар. Яңа туган сабый елаганда: «Тизрәк исем бирергә кирәк, югыйсә ул үзенең исемен сагына», – диләр [4: 151]. Мәҗлескә чакырылган өлкән яшьтәге кешеләрне, мулланы киезгә утырталар. Баланың әтиәнисе дә шунда ук утыра. Яңа туган баланы мендәргә салып, битен каплап алып киләләр. Мулла баланы кулына ала, азан укый, исемен

башта уң колагына, аннары сул колагына әйтә. Шуннан соң барысы бергәләп бал белән чәй эчәләр.

Нократ татарлары да баланы өч тәүлектән артык исемсез тотарга ярамый, югыйсә аны йорт иясе алыштырачак, дип саный.

Урта Урал буе татарларында (Свердловск өлкәсе) исем кушу йоласы түбәндәгечә үтәлә [4: 205–207]. Башта ишекләр, капкалар, мич торбасы ныклап ябыла, янәсе «яңа туган баланың исеме аннан чыгып кача алмасын». Шуннан соң балага бер кашык бал бирәләр, өстәлгә куялар һәм мулла кычкырып азан укый. Тиешлесен үтәгәннән соң, бала көмеш кебек нык булсын өчен, ак металлдан коелган акча сорый. Әгәр аты «туры килсә», бала кайчакта «сөйләшә» башлый, йола үтәлүгә үк йокыга да китә. Елак балага исеме туры килми дип, аны алыштырырга мөмкиннәр. Элегрәк бала таптырган кендек әбигә дә зур хөрмәт күрсәткәннәр, мулла белән беррәттән исем кушарга аны да чакырганнар. Гадәт буенча, исем башта уң колакка, аннары сул колакка әйтелә. Бала туу уңаеннан Свердловск татарлары «туй» уздыралар – якыннарын, күршеләрен җыеп сыйлыйлар. «Туй»га гадәттә ирләре булган хатыннар чакырыла: киләчәктә яңа туган сабыйның да, чакырылган хатыннарныкы кебек, ныклы гаиләсе булыр дип ышаналар. Кунаклар бүләкләр белән киләләр: кызга – күлмәклек, яулык; малайга – биләү, күлмәк. Яңа туган баланың ата-анасы да җавап итеп бүләкләр (чиккән тастымаллар, кендек әбисенә матур күлмәк) өләшә [4: 158].

Вагай татарларында балага өч тапкыр үз исемен генә түгел, әтисенекен дә әйтәләр. Бу – бала көтелмәгәндә үлеп китсә дип эшләнә, югыйсә теге дөньяда ул аларның исемнәрен белмәсә, әти-әнисе белән беркайчан да очраша алмаячак. Себер татарларында балалар еш үлә, моны булдырмас өчен, махсус аерым мәгънәгә ия исемнәр бирелә: Тимергали, Тимербикә, Тимерхан, Тимербәк (тамыры – тимер), Ниязмөхәммәд (Нияз – данлаучы + Мөхәммәд пәйгамбәрнең исеме), Үлмәсбикә, Туктар («туктый»). Тубыл һәм Вагай татарлары, ата-бабаларына аерым хөрмәт йөзеннән, яңа туган балага үлгән бабасы (әбисе) исемен биргәннәр. Традиция буенча, көнкүрештә ул кычкырып әйтелми, «Олата» (бабай), «Инәкә» (әби) кебек сүзләр белән алыштырыла [1: 17].

Бала физик кимчелек, миң белән туган очраклар да булган. Ул чакта баланы учак янына китерәләр, ә исемен торбага кычкыралар. Мулла исем кушканда бала туган айга аеруча зур игътибар бирә. Шул сәбәпле Төмән, Омск, Новосибирск өлкәләрендә яшәгән Себер татарларының исемлекләрендә Рамасан, Сөлхичә, Сафәр, Рәчәп, Шәгъбан, Корман, Корманбикә һ. б. нигезле исемнәр һәм фамилияләр күп очрый.

Новосибирск өлкәсе Бараба татарларында балага исем бирүдә мәҗүсилек традицияләре бик озак саклана: беренче булып күзгә ташланган әйбернең исемен кушу гадәте була. Баланың атасы урамга чыга һәм очып барган торнаны, карганы яки чыркылдый торган

чыпчыкны күрә. Саесканны күрсә, Саескан дип атый, бүре, эт күрсә, Бүре яки Эт дип куша (Бакчакүл) [6: 155–156].

Татарларда төрле хорафатларга ышану да булган. Бала өчен беренче кырык көн аеруча куркыныч саналган. Берничек тә баланың үзен генә калдырырга ярамаган. Кирәк булганда бишектәге баланың мендәр астына пычак, кайчы салганнар, җен-шайтаннар яңа туган баланы алыштырмасын өчен, төрле төстәге тукыма кисәкләреннән эченә дога куеп тегелгән саклагыч бөтиләр элгәннәр. Баланы яман күзләрдән саклаганнар, чит кешеләргә күрсәтмәгәннәр. Баланың маңгаена корым сөрткәннәр, башлыгына зәңгәр төймә тагып куйганнар, исемен үзгәрткәннәр [13: 156]. Мәсәлән, бала зәгыйфь, авыру, күзен ача алмый, ди. Лаеш татарларында тары боткасы пешергәннәр, аны тәлинкәгә салып, мич алдына куйганнар. Шуннан соң хуҗабикә чормага менгән, мич торбасыннан кашыгын төшереп җибәргәндә: «Исемеңне үзгәртәм, хәзер син Миңлегөл», – дип әйткән. Аннары ботканы урамдагы кошларга чыгарып биргән [13: 165]. Дөбьяз татарлары баланың тәнендә кызыл таплар күренү очракларын күз тиюдән дип санаганнар. Алар ботканы тәлинкәсе белән плитәгә куйганнар, торбадан кашыкны шул тәлинкәгә төшергәннәр. Баланы шул кашыктан ашатканнар. Шуннан соң кар беткәнче, яз җиткәнче, кызыл тап беткәнче дип, исемен бозып, вакытлыча үзгәртеп торганнар. Балага вакытлыча «миң» («мин») компонентлы яңа исем биргәннәр. Мәсәлән, ир балаларга – Миңлеәхмәт (Миннәхмәт), Минсалих, кыз балаларга – Миңсылу, Миңзифа дип. Әйтик, Фатыйма исемле кызны – Минехәят, ә Наил исемле малайны Миңлебай дип йөртә башлаганнар. Бастан татарларында гаиләдә сабыйлар гел үлеп барса, малайга Бакый (мәңгелек), кызга Бакыя исеме бирелгән [13: 187].

Кырым татарларында яңа туган балага исем кушу йоласы матур әдәбиятта да чагылыш тапкан. Язучы Сәет Ибраһим әфәнде үзенең әсәрендә исем кушу йоласы атмосферасын бик оста итеп тудыра, аның турында җентекләп сөйли һәм укучыны тәмам җәлеп итә.

«Мазин эфенди бир бакълава, бир де къурабие ашай-ашай къавесини ичип битирген сонъ, Ислям байдан:

– Баланынъ ады къоюладжакъмы ве ады не оладжакъ? – деп сорады.

Ислям бай одадан чыкъып кетти ве эки эли устюнде янъы орьтюлернен сарувлы, къундакълы балыны котерип кельди. Баланынъ къурсачыгъы устюнде учь дане йипек башлы эльбез къатланып къоюлгъан эди.

Имам еринден турды, баланы сол элининъ устюне алып, къыбла тарафкъа дёнди ве Ислям байдан баланынъ ады не оладжагъыны сорады.

– Селим оладжакъ, – деди Ислям бай.

Имам баланынъ онъ къулагъына “Эзан” окъуп, сол къулагъына “Икъамет” кетирип, сонъ баланынъ адыны онъа эшитттирип айтып, бутюн адетлерини япып битирген сонъ:

– Алла хайырлы этсин! Буюсин, оссин, ана-бабасыны севиндирсин! – деп алгъышларнен баланы Ислям байнынъ элине туттырды» [10: 109–110].

Польша-Литва татарларында исем бирү процедурасы ата-ана йортында гадәттә төшке аштан соң уза. «В ней принимали участие имам, два свидетеля и приглашенные гости. Выкупанного и одетого в белое новорожденного клали на подушку на столе таким образом, что его голова была направлена в сторону святынь ислама. На столе кроме ребенка находились: Коран, горящая свеча, хлеб, соль и вода. Имам, декламируя молитву, произносил выбранное для новорожденного имя. Далее, взяв его за указательный палец правой руки, он семь раз повторял шахаду (подтверждение свидетельства). Затем, держа ребенка за правое ухо пальцами правой руки. Имам декламировал азан (призыв к молитве). После такое же действо производилось с левым ухом при декламировании другого призыва к молитве, называемого камет. Обряд заканчивался обстоятельной специальной молитвой» [9: 30].

Шулай итеп, без татарларның төрле этник төркемнәрендә аерым мисаллар аша исем кушу йоласының үтәлешен күзәттек. Бу йолаларда чорның социаль-хокукый нормалары, халыкның үткәндә калган гореф-гадәтләре чагылыш таба.

Татар халкының бүгенге көндәге антропонимиясе килеп чыгышы ягыннан вакыт һәм тел төрлелеге белән характерланган катламнар бердәмлегеннән гыйбарәт. Аның составында төрки-татар, гарәп, фарсы, рус һәм Көнбатыш Европа катламнарын күрергә мөмкин.

Төрки-татар чыгышлы кеше исемнәре аз кулланыла: Алсу, Гүзәл, Чулпан, Алчәчәк, Гөлчәчәк, Тимербикә, Миңсылу, Тимербай, Айсылу. Әлеге антропонимнар апеллятив лексика (космонимия, табигать күренешләре атамалары) нигезендә барлыкка килгән.

Кеше исемнәренең гарәп катламы татар халкы арасында XX гасырның буеннан буена бик популяр була. Яңа туган балага Аллаһы Тәгаләнең, аның пәйгамбәрләренең, туганнарының, сахабәләренең исем-эпитетлары XX гасыр уртасына кадәр актив кушыла, ә икенче яртысыннан әлеге активлык кинәт кими (Мөхәммәд, Мөхәммәдрәхим, Габделхак, Әхмәткәрим, Әхмәтсабир, Мөхәммәдалый, Муса, Гайникамал, Гайнисафа, Вафа, Фатыйма, Гайшә).

Татарлар һәм бохаралылар (бохаралыларга фарсыларны да керткәннәр) арасындагы сәүдә мөнәсәбәтләренең дәвамлы булуы кеше исемнәренең фарсы катламы (Азат, Рөстәм, Нәсим, Фәрхәт) үтеп керүгә ярдәм иткән. *Гөл* «чәчәк», *биби* «ханым», *наз* «грация», *җан* һ. б. исем ясаучы фарсы компонентлары ярдәмендә бик күп татар антропонимнары барлыкка килгән (Гөлнара, Гөлфия, Гөлбаян, Гөлсәгыйдә, Гөлбәйрәм, Гөлләрә, Гөлмәрҗән, Гөлназ, Нәзифә, Рәхимҗан).

Күп кенә Көнбатыш Европа антропонимнары актив кулланылышка рус теле аша кергән һәм халык арасында зур популярлык казанган. Бу катлам татарлар антропонимиясендә XX гасырның икенче яртысында барлыкка килә һәм XXI гасырда актив үсеш кичерә (Альбина,

Денис, Диана, Эльвира, Эдуард, Роберт, Марсель, Алёна, Кристина, Элина, Лилия, Марс, Даниил, Элеонора, Роберт, Модест).

Шулай итеп, аерым мисаллар аша без татарларның төрле төркемнәрендә балага исем кушу йоласын күзәттек. Бу йолаларда чорның социаль-хокукый нормалары, алдагы буыннардан сакланып калган гореф-гадәтләр чагылыш таба. Исемнәр составын күзәтү татар антропонимик системасының никадәр бай һәм күптөрле булуын күрсәтә. Татарлар еш кына балаларына, үзләре белән янәшә яшәгән милләтләрдән үзләштереп, матур татар, гарәп, фарсы исемнәре биргәннәр. Себер татарлары исемнәре Казан, Уфа татар һәм башкортлары исемнәре белән уртак антропонимик корпус тәшкил итә. Бу тарихи традицияләргә, дингә, тел туганлыгына һәм хәзерге социаль шартларга бәйле.

## Әдәбият

1. *Айтбаева Л.Х.* Историко-лингвистическое исследование антропонимии татар междуречья нижней Оби и Иртыша (XX век): автореф. дис. … канд. филол. наук. Тюмень, 2004. 24 с.

2. *Алишина Х.Ч.* Антропонимы сибирских татар XVIII в. // Congressus sptimus internationalis fenno-ugristarum (Debrecen. 27.VIII–2.IX.1990) / regdigunt: László Keresztes, Sánor Maticsák. Debrecen, 1990. 1 B.: Sessiones plenares et symposia: annotations alia.

3. *Баязитова Ф. С.* Татар-мишәр рухи мирасы = Духовное наследие татар-мишарей: Гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. Саранск: Татар газетасы, 2003.

4. *Баязитова Ф.С.* Әстерхан татарлары. Казан, 2002.

5. *Баязитова Ф.С.* Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты. Казан, 1997.

6. *Баязитова Ф.С.* Себер татарлары. Казан, 2001.

7. *Баязитова Ф.С.* Урта Урал (Свердловск өлкәсе) татарлары. Казан, 2002.

8. *Вагапова Ф.Г.* Историко-лингвистический анализ личных имен нижегородских татар XX века: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2002. 28 с.

9. *Гришин Я.Я.* Польско-литовские татары. Наследники Золотой Орды. Научно-популярные очерки. Казань. Татар. кн. изд-во, 1995.

10. *Джемилева А.А.* Сәет Ибраһим әфәнденең «Динсизнинъ акъкъындан имансыз келир» («Динсезгә имансыз җәзасын бирер») хикәясендә сәнгатьчә этнографизм проблемасы // Фәнни Татарстан. 2026. № 1. Б. 105–113.

11. Ислам (Энциклопедический словарь). М.: Наука, 1991. 311 с.

12. *Тимканова Г.Ф.* Историко-лингвистическое исследование личных имен татар г. Тюмени (XX век): монография / науч. ред. д-р филол. наук, проф. Г.Ф. Саттаров. Тюмень: Печатник, 2016. 275 с.

13. *Уразманова Р.К.* Современные обряды татарского народа. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. 143 с.

***Алишина Хәнисә Чайдат кызы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Төмән дәүләт университеты профессоры*

***Алишина Ханиса Чайдатовна,***
*доктор филологических наук,*
*профессор Тюменского государственного университета*
*kaf_tatarlit@utmn.ru*